**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**АКСУБАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**КӘКРЕ КҮЛ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ**

# КАРАРЫ

№ 1 7 ноябрь 2022 ел.

**"Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Кәкре Күл авыл җирлегенең Аксубай Урман заводы бистәсендә гражданнар җыенын билгеләү : үзара салым чараларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча»**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 28.07.2004 №45-ТРЗ Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районының «Кәкре Күл авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 24 статьясы нигезендә КАРАР БИРӘМ:

1. 2022 елның 17 ноябрендә 8 сәгать 00 минутка түбәндәге адрес буенча контора бинасында Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Кәкре Күл авыл җирлегенең Аксубай Урман заводы бистәсендә үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләргә: ТР, Аксубай муниципаль районы, Аксубай Урман заводы поселогында, Лесозавод урамында, 9 йорт .
2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

2023 елда Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Кәкре күл авыл җирлегенең Аксубай Урман заводы бистәсе территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 700 сум күләмендә үзара салым кертү : I төркем инвалидларыннан, Бөек Ватан сугышы ветераннарыннан, көндезге уку формасы буенча укучы студентлардан, Россия Федерациясе Хәрби хезмәтенең срокలы хезмәтендәге хәрбиләрдән, Украинада спецоперациядә катнашырга мобилизацияләнгән гражданнардан һәм аларның гаилә әгъзаларыннан тыш; алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтүгә ризамы:

**Җирлек территориясен төзекләндерүне оештыру:**

- Урам яктыртуын оештыруны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр һәм хезмәтләр сатып алу (килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү).
- Аксубай Урман заводы территориясендә үсентеләр чабу (ягулык-майлау материаллары сатып алу).

**Җирлекнең торак пунктлары чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге;**

- Кышкы чорда автомобиль юлларын карап тоту (ягулык-майлау материаллары сатып алу, урамнарны кардан чистарту, килешү буенча эшләр өчен түләү).

«РИЗА» «КАРШЫ»

3. Әлеге карарны авыл җирлеге мәгълүмат стендларында игълан итәргә.
4. Әлеге карарны Аксубай муниципаль районының рәсми сайтында «Интернет» мәгълүмат-коммуникация челтәрендә һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында урнаштырырга.
5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотам.

Аксубай муниципаль районы
Кәкре Күл авыл җирлеге башлыгы: С.С.Елисеев